**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 26 декабрь № 998

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү турында» 2006 ел, 24 март, 126 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 3 июнь, 370 нче; 2009 ел, 6 апрель, 203 нче; 2012 ел, 23 февраль, 153 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 25 август, 611 нче; 2015 ел, 23 сентябрь, 701 нче; 2015 ел, 1 декабрь, 911 нче; 2016 ел, 22 июнь, 425 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләүгә ташлама-субсидияләр бирү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Ташлама-субсидияләр алу өчен, законнар нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә алар вәкаләтләрен биргән затлар даими яшәү урыны буенча Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге бүлегенә түбәндәгеләрне тапшыра:

ташлама-субсидия бирү турында гариза;

законлы вәкилләрнең яки ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән затларның законнар нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданнар мәнфәгатьләрен белдерүгә вәкаләтләрен раслый торган документлар күчермәләре.

Күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләре өстәмә рәвештә Күчемсез мөлкәт бердәм дәүләт реестрында хокукы теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документлар күчермәләрен кертә.

Законнар нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданнар, аларның законлы вәкилләре яки Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә буенча алар вәкаләтләрен биргән затлар, гариза белән мөрәҗәгать иткәндә, шәхесне таныклый торган документ, банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын, шулай ук гамәлдәге законнарда билгеләнгән очракларда ташлама-субсидияләргә гражданның хокукын раслый торган документ тапшыралар.

Ташлама-субсидия билгеләү һәм алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә җибәрелә ала. Электрон документлар рәвешендә тапшырыла торган гаризалар һәм документлар Россия Федерациясе законнары нигезендә электрон имза белән имзалана һәм электрон саклагычлардан һәм (яки) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып тапшырыла.

Ташлама-субсидия билгеләү һәм алу өчен кирәкле гариза һәм документлар (белешмәләр) электрон документлар рәвешендә тапшырылганда гариза бирүче компенсация билгеләү өчен кирәкле күләмдә һәм максатларда үзенең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын белдерә.

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 ел, 8 декабрь, ТРЗ-63 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы хезмәт ветераннары (алга таба – хезмәт ветераннары) өстәмә рәвештә ташлама-субсидия бирү мәсьәләсен хәл иткәндә исәпкә алына торган керемнәрен раслый торган документлар (Россия Федерациясе Пенсия фондында булган керемнәр турындагы мәгълүматлардан тыш) тапшыра. Хезмәт ветераннары эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан физик зат файдасына күчерелгән түләүләр һәм башка бүләкләүләр суммасы турында гомуми мәгълүматларны раслый торган документлар бирергә хокуклы. Хезмәт ветеранына ташлама-субсидия билгеләү өчен уртача айлык керемне хисаплаганда исәпкә алына торган керемнәр төрләре исемлеге әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтада күрсәтелгән.

Әгәр мөрәҗәгать иткән көндә хезмәт ветераны торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия (алга таба – субсидия) алучы булса, ул керемнәр турында мәгълүматлар бирү бурычыннан азат ителә.

Үзәк бүлеге ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә түбәндәге ташлама-субсидия бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле мәгълүматларны ала:

вәкаләтле оешмалардан «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында белешмәләр;

вәкаләтле оешмалардан федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту хакында мәгълүматлар;

вәкаләтле оешмалардан законнар нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданнар белән даими яшәү урыны буенча бергә теркәлгән гражданнар турында мәгълүматлар;

Күчемсез мөлкәт бердәм дәүләт реестрында аңа хокуклар теркәлгән торак урынга милек хокукы турында белешмәләр.»;

2.4 нче пунктта:

беренче абзацка «ташлама-субсидия алу өчен сәбәпләр үзгәрү» сүзләреннән соң «, ташлама алучының яшәү урынын алыштыруы» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташлама-субсидия бирү, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен бурычлар булганда, җыелган бурычларны каплаганчы яки ташлама алучы аны каплау буенча килешү төзегәндә һәм (яки) үтәгәндә туктатылып тора.»;

3.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Инвалид бала булган гаилә составына даими яшәү урыны буенча инвалид бала белән бергә торучы гражданнар кертелә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында мәгълүмати хезмәттәшлек итү турында» 2005 ел, 22 гыйнвар, 20 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 30 май, 245 нче; 2005 ел, 17 ноябрь, 539 нчы; 2006 ел, 16 ноябрь, 547 нче; 2007 ел, 5 февраль, 33 нче; 2007 ел, 28 март, 113 нче; 2007 ел, 13 июль, 295 нче; 2008 ел, 31 гыйнвар, 48 нче; 2008 ел, 12 март, 157 нче; 2008 ел, 29 май, 344 нче; 2009 ел, 4 февраль, 64 нче; 2009 ел, 21 сентябрь, 654 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2013 ел, 21 октябрь, 781 нче; 2015 ел, 3 июль, 483 нче; 2015 ел, 22 август, 612 нче; 2015 ел, 30 декабрь,1033 нче; 2016 ел, 9 март, 132 нче; 2016 ел, 13 май, 306 нчы; 2016 ел, 7 июль, 462 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр һәм айлык акчалата түләүләр бирү системасында катнашучы оешмалар арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның уникенче һәм егерме алтынчы абзацларын төшереп калдырырга;

6 нчы пунктта:

таблицада:

4 нче пунктны төшереп калдырырга;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «8. | ИК, ТКХК, ХҮ | Түбәндәгеләр турында мәгълүматларны исәпләү һәм тапшыру:<br>гамәлдә күрсәтелгән торак-коммуналь хезмәтләр, антенна хезмәтләре өчен түләүләр, персональләштерелгән социаль счетлар яктылыгында коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары;<br>рәттән 2 айга, агымдагы ай өчен бурычларны кертеп, торак | электрон | хисап аеннан соң килә торган айның 3сенә кадәр | МПРҮ бүлекләре»; |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | урыннар һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычлар булу факты;<br>гражданнар тарафыннан аларны түләү буенча килешүләр төзү һәм (яки) үтәү;<br>коммуналь хезмәтләрне өздерү факты;<br>коммуналь хезмәтләрне тоташтыру факты. | | | |

25 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «25. | ҖҮО | Балаларына карата ата-ана хокукларыннан мәхрүм ителгән гражданнар турында, шулай ук тәрбиягә бала алган ата-аналар яисә опекуннар булган гражданнар хакында мәгълүмат | документлар | җирле үзидарә органнарына документлар кертелгән көннән соң 5 көн эчендә | СЯТО, МПРҮ бүлекләре |
| | | Түбәндәгеләрне туктату турында мәгълүматлар:<br>Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә ИК эшчәнлеген;<br>халыкка коммуналь хезмәтләр күрсәтү буенча ТКХК эшчәнлеген;<br>идарә яки ресурслар белән тәэмин итү оешмалары белән килешү нигезендә торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрне исәпләү буенча ХҮ эшчәнлеген | электрон, кәгазь | хисап аеның 1сенә кадәр | МПРҮ бүлекләре»; |

өченче абзацны төшереп калдырырга.

3. Әлеге карар үз көченә кергән көндә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә ташлама-субсидия алучы гражданнар тарафыннан күпфатирлы йорттагы торак урыннарга милек хокукын раслау, бу карар үз көченә кергән көннән башлап,

12 ай эчендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары раслаган график буенча гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2016\998.doc